Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

2023 елның 28 апреле № 80

**2023 елда Тәмте авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнарга, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына, Тәмте авыл җирлеге Уставы нигезендә Тәмте авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. 2023 елда эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча ТР Кама Тамагы МР Тәмте авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында һәм муниципаль органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрелмәскә мөмкин.
2. Әлеге карарның 1 пункты Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына билгеләнгәндә кулланылмый
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге башлыгы,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге Советы рәисе
И.А.Зиновьев